**МИНИСТЕРСТВО ПО ДЕЛАМ МОЛОДЕЖИ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЯШЬЛӘР ЭШЛӘРЕ МИНИСТРЛЫГЫ**

**ПРИКАЗ** **БОЕРЫК**

**_____18.08.2023__________** **Казан** **№_______308_________**

Татарстан Республикасы
Яшьләр эшләре министрлыгының
ведомство бүләкләре турында

Мотивация системасын камилләштерү һәм яшьләр сәясәте өлкәсендә эшләүчеләрне бүләкләү, шулай ук яшьләр сәясәтен үстерүдә һәм камилләштерүдә актив катнашучы башка затларны тәбрикләү максатыннан, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2018 елның 11 июлендәге «Татарстан Республикасы Яшьләр эшләре Министрлыгы мәсьәләләре» 563 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы Яшьләр эшләре Министрлыгы турында нигезләмәнең 3.4. пункты нигезендә боерам:

1. Татарстан Республикасы Яшьләр эшләре Министрлыгының ведомство бүләкләрен гамәлгә куярга:

«Яшьләр сәясәтен гамәлгә ашырудагы хезмәтләре өчен» Алтын билгесе;

«Яшьләр сәясәтен гамәлгә ашырудагы хезмәтләре өчен» Көмеш билгесе;

Татарстан Республикасы Яшьләр эшләре Министрлыгының Мактау грамотасы;

Татарстан Республикасы Яшьләр эшләре министры Рәхмәте;

«Татарстан Республикасы студентлар отрядлары хәрәкәте үсешенә керткән өлеше өчен» Мактау билгесе.

2. Теркәлгәннәрне расларга:

Татарстан Республикасы Яшьләр эшләре Министрлыгының ведомство бүләкләре турында нигезләмә;

Татарстан Республикасы Яшьләр эшләре Министрлыгының ведомство бүләкләре тасвирламасы.

3. Татарстан Республикасы Яшьләр эшләре Министрлыгының оештыру эшләре бүлегенә:

Бүләкләү документларын кабул итү, бүләкләүгә материаллар әзерләү, Татарстан Республикасы Яшьләр эшләре Министрлыгының ведомство бүләкләрен рәсмиләштерү һәм тапшыру, аларның исәпкә алып баруны оештырырга.

4. Татарстан Республикасы Яшьләр эшләре Министрлыгының бухгалтерлык хисабы һәм дәүләт заказы бүлегенә Татарстан Республикасы Яшьләр эшләре Министрлыгы сметасында Министрлыкның ведомство бүләкләре

бланклары һәм билгеләрен әзерләү өчен, «Татарстан Республикасы студентлар отрядлары хәрәкәтен үстерүдә керткән өлеше өчен» Мактау билгесен әзерләүне финанслауга чыгымнарны кертмичә, финанс чыгымнары каралырга тиеш.

5. Татарстан Республикасы Яшьләр эшләре Министрлыгының массакүләм мәгълүмат чаралары белән хезмәттәшлек буенча әйдәүче белгеченә (З.Ф.Гыймазовага) әлеге боерыкны Татарстан Республикасы Яшьләр эшләре Министрлыгының «Интернет» мәгълүмати-телекоммуникация челтәрендәге рәсми сайтына урнаштырырга.

6. «Татарстан Республикасы студентлар хезмәт отрядлары республика үзәге» дәүләт бюджет учреждениесенә ел саен «Татарстан Республикасы студентлар отрядлары хәрәкәтен үстерүдә керткән өлеше өчен» Мактау билгесен әзерләүгә финанс чыгымнарын сметада карарга.

7. Татарстан Республикасы Яшьләр эшләре Министрлыгының 2019 елның 6 июнендәге «Татарстан Республикасы Яшьләр эшләре Министрлыгының ведомство бүләкләре турында» 181 номерлы боерыгы үз көчен югалткан дип танырга.

8. Әлеге боерыкның үтәлешен тикшерүне Министрлыкның эшләрен алып баручы Р.Ф.Абдрахмановка йөкләргә.

**Министр** **Р.Н.Садыйков**

Татарстан Республикасы
Яшьләр эшләре
Министрлыгы боерыгы
белән расланды
«__» _____ 20__ ел № _

Татарстан Республикасы Яшьләр эшләре Министрлыгының
ведомство бүләкләре турында
Нигезләмәсе

I. Төп нигезләмәләр

1. Әлеге Нигезләмә Татарстан Республикасы Яшьләр эшләре Министрлыгының ведомство бүләкләре(алга таба-ведомство бүләкләре, Министрлык) белән бүләкләүгә тәкъдим итү тәртибен, ведомство бүләкләре белән бүләкләү тәртибен билгели.

1.2. Ведомство бүләкләре әлеге Нигезләмәдә күрсәтелгән затларны кызыксындыру формасы булып тора.

1.3. Ведомство бүләкләре белән бүләкләнәләр:

а) Министрлыкта Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәте вазыйфаларын биләүче Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәткәрләре, шулай ук Министрлык хезмәткәрләре;

б) Министрлык карамагындагы оешмаларның билгеләнгән өлкәдә эшчәнлек алып баручы хезмәткәрләре;

в) Татарстан Республикасы дәүләт вазыйфаларын биләүче затлар, Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәткәрләре, Татарстан Республикасы дәүләт власте органнары хезмәткәрләре һәм министрлыкның билгеләнгән өлкәсендә эшчәнлек алып баручы алар карамагындагы оешмалар;

г) Татарстан Республикасы муниципаль вазыйфалар биләүче затлар, Татарстан Республикасы муниципаль хезмәткәрләр, Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре җирле үзидарә органнары хезмәткәрләре һәм Министрлыкны алып баруда билгеләнгән өлкәдә эшчәнлек алып баручы алар карамагындагы оешмалар.

д) гражданнар, коллективлар һәм оешмалар хезмәткәрләре, иҗтимагый оешмалар

1.3.1. Бүләкләүләр билгеләнә:

а) Татарстан Республикасында яшьләр сәясәте өлкәсендә хезмәтләр өчен;

б) нәтиҗәле һәм тиңдәшсез дәүләт граждан хезмәте өчен;

в) күпьеллык һәм намуслы хезмәте өчен;

г) Министрлыкка йөкләнгән мәсьәләләрне чишүдә актив булышлык итү өчен;

д) Татарстан Республикасы территориясендә яшьләр сәясәте стратегиясен үстерү һәм гамәлгә ашыруда хезмәтләр өчен;

е) Татарстан Республикасында яшьләр сәясәте тармагы үсешендә мөһим өлеше өчен, тармак проектлары, программаларына спонсорлык ярдәме һәм хәйриячелек;

ж) Татарстан Республикасы территориясендә студентларның хезмәт отрядлары үсешендә зур өлеш кертү өчен.

1.4. Ведомство бүләкләре белән бүләкләнүгә кандидатлар (алга таба-кандидат) түбәндәге таләпләргә туры килергә тиеш:

1.4.1. Эш стажы:

а) «Татарстан Республикасында яшьләр сәясәтен гамәлгә ашырудагы хезмәтләре өчен» Алтын билгесе белән бүләкләнү өчен – яшьләр сәясәте өлкәсендә 10 елдан да ким булмаган эш стажы;

б) «Татарстан Республикасында яшьләр сәясәтен гамәлгә ашырудагы хезмәтләре өчен» көмеш билгесе белән бүләкләнү өчен – яшьләр сәясәте өлкәсендә җидедән дә ким булмаган эш стажы;

в) Татарстан Республикасы Яшьләр эшләре Министрлыгының Мактау грамотасы белән бүләкләнү өчен – яшьләр сәясәте өлкәсендә өч елдан да ким булмаган эш стажы(алга таба-Мактау грамотасы);

г) «Татарстан Республикасы студентлар отрядлары хәрәкәте үсешенә керткән өлеше өчен» Мактау билгесе белән бүләкләү өчен студент хезмәт отрядлары өлкәсендә – өч елдан да ким булмаган стаж(алга таба – Мактау билгесе);

е) Татарстан Республикасы Яшьләр эшләре министры рәхмәте белән бүләкләнү өчен – яшьләр сәясәте өлкәсендә бердән дә ким булмаган эш стажы

(алга таба- Министр рәхмәте)

1.4.2. Булырга тиеш:

а) Әлеге эшчәнлек өлкәсендә һөнәри хезмәтләр (нәтиҗәле һәм намуслы хезмәт эшчәнлеге өчен бүләкләре, россиякүләм, региональ һәм муниципаль һөнәри конкурсларда җиңү турында, һ.б. белешмәләр);

б) Көмеш билге – Алтын билге белән бүләкләнүгә тәкъдим ителгәндә;

в) Мактау грамотасы – Көмеш билге белән бүләкләнүгә тәкъдим ителгәндә;

г) Министр Рәхмәте – Мактау грамотасы белән бүләкләнүгә тәкъдим ителгәндә;

д) студентларның хезмәт отрядлары өлкәсендә һөнәри уңышлар – Мактау билгесе белән бүләкләнүгә тәкъдим ителгәндә.

1.4.3. Булмаска тиеш:

а) закон нигезендә билгеләнгән хөкем ителү алынмаган яки түләнмәгән;

б) үтәлмәгән дисциплина җәзасы.

1.5. Мактау билгесе түбәндәге квота буенча бүленә:

а) Студентлар хезмәт отрядларының 50 катнашучысына - бер Мактау билгесе;

б) Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре штабының 50 катнашучысына - бер Мактау билгесе.

1.5.1. Студентлар хезмәт отрядлары штаблары өчен юбилей елында квота ике тапкырга арта.

II. Ведомство бүләкләренә тәкъдим итү тәртибе

2.1. Ведомство бүләге белән бүләкләү турында карарны Татарстан Республикасы Яшьләр эшләре Министрлыгы комиссиясе (алга таба- комиссия) Татарстан Республикасы Яшьләр эшләре министры (алга таба-Министр) исеменә ирекле формада төзелгән юллама нигезендә кабул итә.

2.2. Юллама  ведомство бүләге белән бүләкләүгә тәкъдим ителгән затның төп эш (хезмәт) урыныннан бирелә.

Юллама бирү турында карар  ведомство бүләге белән бүләкләүгә тәкъдим ителгән затның төп эш (хезмәт) урыны буенча коллектив тарафыннан кабул ителә һәм оешманың  коллегиаль органы( органы) тарафыннан карала.

.2.3. Юлламага беркетеләләр:

а) Әлеге Нигезләмәнең 1 нче кушымтасында күрсәтелгә форма буенча кешене ведомство бүләге белән бүләкләүгә тәкъдим итү(алга таба –тәкъдим итү). Тәкъдим итү  юллама җибәргән оешма(орган) җитәкчесе, шулай ук коллектив җыелышы рәисе тарафыннан имзалана һәм печать белән(булган очракта) раслана.

б) ведомство бүләгенә тәкъдим ителгән затның  ведомство бүләге белән бүләкләү турындагы документларга кертелгән  шәхси мәгълүматларын эшкәртүгә әлеге Нигезләмәнең 2нче кушымтасында күрсәтелгән формада  язмача ризалыгы.

в)ведомство бүләгенә тәкъдим ителгән затның, субъект тарафыннан шәхси мәгълүматларны  таратуга рөхсәт ителгән  шәхси мәгълүматларын  эшкәртүгә әлеге Нигезләмәнең 2нче кушымтасында күрсәтелгән формада  язмача ризалыгы.

2.3.1. Яшьләр көнен бәйрәм итүгә багышланган ведомство бүләкләре белән бүләкләү турындагы документлар министрлыкка бәйрәмгә кадәр 90 көннән дә соңга калмыйча, ә юбилей, истәлекле даталарга тиешле дата башланганчы 60 көннән дә соңга калмыйча тапшырылырга тиеш.

2.4. Ведомство бүләге белән бүләкләүгә кандидат турында локументлар Министрлык боерыгы белән төзелгән  Комиссия тарафыннан карала.

Комиссия рәисе – министр.

2.5. Комиссия тарафыннан ведомство бүләге белән бүләкләү турындагы документларны карау срогы Министрлыкта теркәлгән көннән 30 эш көненнән дә артмаска тиеш. Бүләкләү турындагы документлар кергән  көндә  теркәлә. Документлар ял (бәйрәм) көнендә керсәләр,  ял(бәйрәм) көннән соң  эш көнендә, ә эш көне тәмамланганнан соң керсәләр, алдагы эш көнендә теркәләләр.

2.6. Комиссия карары карар кабул иткән көннән алып җиде көн эчендә беркетмә белән рәсмиләштерелә.

Тәкъдим ителгән документлар нигезендә Комиссия  кандидатны ведомство бүләге белән бүләкләү турында  яки, әлеге Нигезләмәдә  билгеләнгән таләпләрне исәпкә алып,  кандидатны  ведомство бүләге белән бүләкләүне кире кагу турында карар кабул итә.

Бүләкләүне кире кагу турында карар кабул ителгән  яки әлеге Нигезләмә таләпләрен бозып күрсәтелгән затларны бүләкләү турындагы документлар карар кабул ителгән көннән алып җиде көн эчендә кире кайтарылырга тиеш.

2.7. Кандидатны ведомство бүләге белән бүләкләү турындагы карар Министрлык боерыгы белән  Комиссия карар кабул иткән вакыттан җиде көн

эчендә рәсмиләштерелә. Алтын билге, Көмеш билге, Мактау билгесе, Мактау грамотасы һәм Министрлык Рәхмәте таныклыгы министр тарафыннан имзалана һәм печать белән раслана.

2.8. Комиссия тарафыннан бүләкләү кире кагылган кандидатны кабат ведомство бүләгенә тәкъдим итү әлеге карар кабул ителү көннән бер ел үткәннән соң мөмкин.

## III. Ведомство бүләге белән бүләкләү тәртибе

3.1. Ведомство бүләкләрен министр яки аның кушуы буенча тармакны күзәтүче министр урынбасары яисә министр исеменнән оешмаларның (органнарның) башка вазыйфаи затлары тапшыра.

3.2. Ведомство бүләкләре белән бүләкләү башкарыла:

а) бер еллык эш йомгакларын үткәргәндә;

б) һөнәри бәйрәмнәрне, оешмаларның һәм органнарның истәлекле һәм юбилей даталарын бәйрәм иткәндә.

Ведомство бүләкләре белән бүләкләү кандидатның юбилей даталарына (30 ел, 40 ел, 50 ел һәм һәр 10 ел тууына), оешмаларның юбилей даталарына (10 ел, 20 ел һәм оешудан соң һәр 10 ел үтүгә).

Ведомство бүләкләре белән бүләкләү тантаналы шартларда гамәлгә ашырыла ала.

3.3. Алтын билге, көмеш билге һәм мактаулы билге белән бергә министр имзалаган таныклыклар бирелә.

3.4. Министрлыкта Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәте вазыйфаларын биләүче Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәткәрләренә, шулай ук ведомство бүләкләре белән бүләкләнгән Министрлык хезмәткәрләренә хезмәт китабына ведомство бүләкләре белән бүләкләү турында язма кертелә.

3.5. Чираттагы ведомство бүләге алдагы бүләкләүдән соң ике елдан да иртәрәк бирелә алмый.

3.6. Бер төр ведомство бүләге белән кабат бүләкләү башкарылмый. Министрның Рәхмәт хаты гына искәрмә булып тора.

3.7. Ведомство бүләген яки аңа таныклыкны югалткан очракта, Министрлыкның дәүләт хезмәте, кадрлар һәм юридик эш бүлеге бүләкләү турында Министрлыкның Герб мөһере белән расланган боерыктан күчермә бирә. Ведомство бүләкләренең дубликатлары бирелми.

3.8. Ведомство бүләкләре белән бүләкләнгән затларның һәм Министрлыкның ведомство бүләген алуга тәкъдим ителгән кандидатларның шәхси мәгълүматлары 2006 елның 27 июлендәге 152 номерлы Федераль законның 5 маддәсенә ярашлы

рәвештә Министрлыкта кәгазь һәм (яки) электрон форматта, шул исәптән Министрлыкның мәгълүмат системаларында саклана.

3.9. Ведомство бүләкләре белән бүләкләнгән затларны бүләкләү һәм исәпкә алу эшен Министрлык оештыра.

Татарстан Республикасы Яшьләр эшләре министрлыгының ведомство бүләкләре турындагы Нигезләмәсенә
Кушымта 1
«____»____________ел № ____

Татарстан Республикасы Яшьләр эшләре министрлыгының
ведомство бүләге белән бүләкләүгә
Күрсәтмә

Фото
3см х 4см

1. Фамилия, исем, әтисе исеме (булган очракта)
________________________________________________
(паспорт буенча рус һәм татар телендә тутырыла)

2. Туу көне, ае, елы ________________________

3. Туу урыны ________________________________

4. Белеме ____________________________________________
(нинди уку йортын тәмамлаган һәм кайсы елда)

5. Белем дәрәҗәсе, фәнни исеме __________________________________
6. Яшәү урыны адресы_______________________________________
7. Эш урыны, биләгән вазыйфасы ___________________________
8. Гомуми эш стажы ____________________________________
9. Әлеге тармакта эш стажы
________________________________________________
10. Әлеге коллективта эш стажы_________________________________
11.Бүләкләнгән дәүләт, ведомство бүләкләре
________________________________________________________
12. Хезмәт эшчәнлеге (шул исәптән югары уку йортларында һәм урта махсус уку йортларында уку, хәрби хезмәт):

| Ай һәм ел | | Оешма белән вазыйфаны күрсәтеп | Оешманың урнашу урыны |
|---|---|---|---|
| керү | китү | | |
| | | | |
| | | | |

Әлеге күрсәтмәнең 12 пунктында күрсәтелгән хезмәт эшчәнлеге турында мәгълүматлар хезмәт китабы мәгълүматларына туры килә

_______________________________________________________________

М.П. (кадрлар хезмәте җитәкчесенең вазыйфасы, имзасы, фамилиясе, инициаллары)

13. Бүләкләүгә тәкъдим ителгән кешенең конкрет хезмәтләрен күрсәтүче характеристика:

_______________________________________________________________

_______________________________________________________________ кандидатурасы

(фамилия, исем, әтисе исеме (булган очракта)

хезмәткәрләр коллективы җыелышы тарафыннан тәкъдим ителгән_______________________________________________________________

(оешма исеме)

_______________________________________________________________

(хезмәткәр коллективы, аның советы яки коллегиясе җыелу датасы, протокол номеры)

| | |
|---|---|
| Оешма җитәкчесе | Хезмәткәрләр коллективы җыелышы рәисе |
| ____________<br>(имза) | _________________<br>(имза) |
| __________________________<br>(фамилия һәм инициаллар) | _____________________________<br>(фамилия һәм инициаллар) |
| М.П. | М.П. (булган очракта) |
| «__» _____________ ел. | «__»___________ ел. |

Татарстан Республикасы Яшьләр
эшләре министрлыгының
ведомство бүләкләре турындагы
Нигезләмәсенә
Кушымта 2
«____»____________ел. № ____

Россия Федерациясе законнары нигезендә ведомство бүләге белән бүләкләү турындагы документларда булган шәхси мәгълүматны эшкәртү өчен Ведомство бүләге белән бүләкләүгә тәкъдим ителгән кешенең ризалыгы

Мин,
______________________________________________________________________________,
(фамилия, имя, атасы исеме (булган очракта)
________________________________________________адресы буенча яшәүче,
шәхесемне раслаучы төп документ ________________________________
______________________________________________________________________________,
(документ төре, сериясе, номеры, кем тарафыннан һәм кайчан бирелгән)

2006 елның 27 июлендәге 152-ФЗ номерлы «Шәхси мәгълүматлар турында» Федераль законның 9 маддәсе нигезендә Татарстан Республикасы Яшьләр эшләре министрлыгына (адрес: 420000, Казан ш., Сафьян ур., 5) (алга таба – «Оператор») Татарстан Республикасы Яшьләр эшләре министрлыгының ведомство бүләге белән бүләкләү мәсьәләсен карау максатыннан, автоматлаштырылган һәм автоматлаштыру чараларын кулланмыйча, үз шәхси мәгълүматларымны эшкәртүгә, шул исәптән җыю, системалаштыру, туплау, саклау, төгәлләү (яңарту, үзгәртү), куллану, шәхессезләндерү, блокировкалау, юк итүгә үз ризалыгымны бирәм.

Эшкәртүгә ризалык бирелә торган шәхси мәгълүматлар исемлеге: фамилия, исем, атасы исеме (булган очракта), җенес, туган көне һәм урыны, гражданлыгы, шәхесне раслаучы документ реквизитлары (документ төре, аның сериясе һәм номеры, кем тарафыннан һәм кайчан бирелгән), яшәү урыны, теркәлү урыны, телефон номеры (шул исәптән мобиль телефон), электрон почта адресы, хезмәт эшчәнлеге турында мәгълүмат, гаилә хәле, хезмәт стажы, белеме, дәүләт, ведомство бүләкләре белән бүләкләү турында мәгълүмат).

Әлеге Ризалык имзаланган көннән алып 1 (бер) ел гамәлдә тора.

Әлеге Ризалык операторга гади язма формада гариза бирү юлы белән кире кайтарыла ала.

Шәхси мәгълүматларын эшкәртүгә ризалык кире алынган очракта, оператор аларны эшкәртүне туктатырга яки күрсәтелгән бәяләмә килгән көннән алып утыз көннән дә артмаган вакыт эчендә мондый эшкәртүне туктатуны тәэмин итәргә тиеш (шәхси мәгълүматларны эшкәртү оператор кушуы буенча эш итүче башка кеше тарафыннан башкарылган очракта) һәм шәхси мәгълүматларны эшкәртү максатларында шәхси мәгълүматларны саклау таләп ителми икән, шәхси мәгълүматларны юк итәргә яки аларны юк итүне тәэмин итәргә тиеш (шәхси мәгълүматларны эшкәртүне оператор кушуы буенча эшләүче башка кеше башкарган очракта).

Күрсәтелгән вакыт эчендә шәхси мәгълүматны юк итү мөмкинлеге булмаган очракта оператор мондый персональ мәгълүматны туктата яки аларны туктатуны тәэмин итә (шәхси мәгълүматны эшкәртү оператор кушуы буенча эш итүче башка кеше тарафыннан башкарылган очракта) һәм шәхси мәгълүматны алты айдан да артык булмаган вакыт эчендә юк итүне тәэмин итә.

Бу хакта 2006 елның 27 июлендәге 152-ФЗ номерлы «Шәхси мәгълүматлар турында»гы Федераль закон нигезләмәләре белән танышканымны раслыйм, шәхси мәгълүматларны яклау өлкәсендәге хокуклар һәм бурычлар миңа аңлатылды.

_______________________________________________/__________________

(фамилия, исем, атасы исеме (булган очракта) һәм шәхси мәгълүмат субъектының имзасы) (Дата)

Татарстан Республикасы Яшьләр эшләре министрлыгының ведомство бүләкләре турындагы Нигезләмәсенә
Кушымта 3
«____»____________ № ____

Шәхси мәгълүматны тарату өчен субъект рөхсәт иткән шәхси мәгълүматны эшкәртүгә ризалык

Мин,
_______________________________________________________________________________,

(фамилия, исем, атасы исеме (булган очракта)

_______________________________________________________________________________,

(почта адресы)

_______________________________________________________________________________,

(электрон почта адресы)

_______________________________________________________________________________,

(телефон номеры)

Мин «Шәхси мәгълүматлар турында»гы 2006 елның 27 июлендәге 152-ФЗ номерлы Федераль законның 10.1 маддәсе нигезендә оештыручыларга – Татарстан Республикасы Яшьләр эшләре министрлыгына (Адрес: 420000, Казан ш., Сафьян ур., 5) ведомство бүләге белән бүләкләү мәсьәләсен карау максатыннан шәхси мәгълүматларымны таратуга (тапшыруга, бирүгә), ведомство бүләге белән бүләкләү мәсьәләсен карау, шулай ук бүләкләү тантанасын үткәрү турында мәгълүматны рәсми сайтта бастырып чыгару максатыннан үз ризалыгымны бирәм.

Эшкәртүгә ризалык бирелә торган шәхси мәгъләүматларның категориясе һәм исемлеге

| N п/п | Шәхси белешмәләр | Ризалык | |
|---|---|---|---|
| | | бар | юк |
| Гомуми шәхси белешмәләр | | | |
| 1. | Фамилия | | |
| 2. | Исем | | |
| 3. | Атасы исеме (булган очракта) | | |
| 4. | Җенес | | |
| 5. | Гражданлыгы | | |

| | | | |
|---|---|---|---|
| 6. | Туу көне, ае, елы, урыны | | |
| 7. | Шәхесне раслаучы документ реквизитлары(документ төре, аның сериясе һәм номеры, кем тарафыннан һәм кайчан бирелгән) | | |
| 8. | Яшәү урыны, теркәлү урыны | | |
| 9. | Телефон номеры, шул исәптән мобиль телефон | | |
| 10. | Электрон почта адресы | | |
| 11. | Хезмәт эшчәнлеге, белеме турында белешмә | | |
| 12. | Эш стажы | | |
| 13. | Белеме турында белешмә | | |
| 14. | Гаилә хәле | | |
| 15. | Дәүләт, ведомство бүләкләре белән бүләкләнү турында белешмә | | |

Шартлар һәм тыюлар билгеләнгән шәхси мәгълүматлар категорияләре һәм исемлеге (шәхси мәгълүматлар субъекты теләге буенча тутырыла)

| N п/п | Шәхси белешмәләр | Билгеләнә торган шартлар һәм тыюлар исемлеге |
|---|---|---|
| 1. (Шәхси белешмәләр категорияләре) | | |
| | (Шәхси белешмәләр исемлеге) | |

Чикләнмәгән төркем кешеләргә керү һәм шәхси мәгълүмат субъектының шәхси белешмәләре белән башка гамәлләр башкарылачак операторларның мәгълүмати ресурслары турында мәгълүмат: https://minmol.tatarstan.ru/.

Шәхси мәгълүмат субъекты әлеге ризалыкны операторларга язмача хәбәр итеп, үз шәхси мәгълүматларын эшкәртүдән кире алырга хокуклы.

Шәхси мәгълүматны эшкәртүгә ризалык кире алынган очракта, чакыру кабул ителгән көннән алып утыз көннән дә артмаган вакыт эчендә оператор аларны эшкәртүдән туктатырга яки мондый эшкәртүне туктатуны тәэмин итәргә (шәхси мәгълүматны эшкәртү оператор кушуы буенча эш итүче башка кеше тарафыннан башкарылган очракта) һәм шәхси мәгълүматны эшкәртү максатларында шәхси мәгълүматны саклау таләп ителмәсә, шәхси мәгълүматны юк итәргә яки аларны юк

итүне тәэмин итәргә тиеш (шәхси мәгълүматны эшкәртү оператор кушуы буенча эш итүче башка кеше тарафыннан башкарылган очракта).

Әгәр күрсәтелгән вакыт эчендә шәхси мәгълүматны юк итү мөмкинлеге булмаса, оператор мондый шәхси мәгълүматны туктата яки аларны туктатуны тәэмин итә (шәхси мәгълүматны эшкәртү оператор кушуы буенча эш итүче башка кеше тарафыннан башкарылган очракта) һәм шәхси мәгълүматны алты айдан да артык булмаган вакыт эчендә юк итүне тәэмин итә.

Бу хакта 2006 елның 27 июлендәге 152-ФЗ номерлы «Шәхси мәгълүматлар турында»гы Федераль закон нигезләмәләре белән танышканымны раслыйм, шәхси мәгълүматларны яклау өлкәсендәге хокуклар һәм бурычлар миңа аңлатылды.

_______________________________________________________/____________________

(фамилия, исем, атасы исеме (булган очракта) һәм шәхси мәгълүмат субъектының имзасы) (Дата)

Искәрмә. Шартлар һәм тыюлар операторларның шәхси мәгълүматны тарату һәм (яки) чикләнмәгән яки билгеле бер төркем кешеләргә бирү буенча гамәлләр башкаруын чикләүне яки тыюны күздә тота.

Өстәмә рәвештә, алынган шәхси мәгълүматны шәхси белешмәләр эшкәртүне гамәлгә ашыручы операторлар тарафыннан мәгълүматка төгәл билгеләнгән хезмәткәрләр өчен генә, яки мәгълүмати-телекоммуникация челтәрләрен кулланып, яки алынган шәхси мәгълүматны тапшырмыйча гына керүне тәэмин иткән, аның эчке челтәре аша гына тапшыра ала торган шартлар күрсәтелергә мөмкин.

Татарстан Республикасы
Яшьләр эшләре
министрлыгының
«__» _____ 20__ ел № ___
боерыгы белән расланган

## I. Татарстан Республикасы Яшьләр эшләре министрлыгының ведомство бүләкләре тасвирламасы

«Татарстан Республикасы яшьләр сәясәтен гамәлгә ашыруда казанышлары өчен» алтын билгесе (алга таба – алтын билге) сары металл эретмәсеннән эшләнә.

«Татарстан Республикасы яшьләр сәясәтен гамәлгә ашыруда казанышлары өчен» көмеш билгесе (алга таба – Көмеш билге) көмеш металл эретмәсеннән эшләнә.

Алтын билге һәм Көмеш билге диаметры 15 ммлы, түгәрәкләнгән почмаклары булган квадрат формасында.


Алтын билгенең һәм көмеш билгенең алгы ягында үзәктә график элементларның динамик схемасын тәшкил иткән «М» баш хәрефе сурәтләнгән.

Билге әйләнәсе буенча түбәндәге язулар урнаштырылган: сул якта «КАЗАНЫШЛАР ӨЧЕН», өстә «ГАМӘЛГӘ АШЫРУДА», уң якта «ЯШЬЛӘР», аскы якта «ТР СӘЯСӘТЕ».

Алтын билгенең һәм Көмеш билгенең арткы ягында аларны киемгә каптыру өчен махсус йозак белән тоткыч урнаштырылган.

Алтын билге һәм Көмеш билге күкрәкнең сул ягында Россия Федерациясе дәүләт бүләкләреннән, Татарстан Республикасы дәүләт бүләкләреннән түбәнрәк дәрәҗәдә йөртелә.

Алтын билге макеты




Көмеш билге макеты



## II. «Татарстан Республикасы яшьләр сәясәтен гамәлгә ашыруда казанышлары өчен» алтын һәм көмеш билгегә таныклык бланкы үрнәге

### Таныклыкның тышкы өлеше

| | |
|---|---|
| | «Татарстан Республикасы яшьләр сәясәтен гамәлгә ашыруда казанышлары өчен» билгесы рәсеме |

### Таныклыкның эчке өлеше

| | |
|---|---|
| Татарстан Республикасы яшьләр эшләре министрлыгы<br><br>“Татарстан Республикасы яшьләр сәясәтен гамәлгә ашыруда казанышлары өчен» билгесе белән бүләкләнә<br><br>____________________________________<br>(Ф.И.О.( атасының исеме - булган очракта)<br><br>Татарстан Республикасы яшьләр эшләре министрлыгы боерыгы ____________№______.<br><br>Министр_________ ______________________ _________ __________________<br>(имза) (Ф.И.О.( атасының исеме - булган очракта)<br>М.П. | Министерство по делам молодежи Республики Татарстан<br><br>Награжден (а) ____________ знаком «За заслуги в реализации молодежной политики Республики Татарстан»<br><br>______________________________________________<br>(Ф.И.О.(отчество – при наличии)<br><br>Приказ Министерства по делам молодежи Республики Татарстан от___________ _№____<br><br>Министр _________ _____________________<br>(подпись) (Ф.И.О. отчество – при наличии)<br><br>М.П. |

## III. «Татарстан Республикасы студентлар хезмәт отрядлары хәрәкәтен үстерүгә керткән өлеше өчен» мактау билгесе таныклыгы бланкы үрнәге

МИНИСТЕРСТВО ПО ДЕЛАМ МОЛОДЕЖИ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

УДОСТОВЕРЕНИЕ
К МАКТАУНОМУ ЗНАКУ

ЗА ВКЛАД В РАЗВИТИЕ
СТУДЕНЧЕСКИХ ТРУДОВЫХ ОТРЯДОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

КАЗАНЬ

---

Татарстан Республикасы яшьләр
эшләре министрлыгы

________________________________
(фамилия)

________________________________
(исем)

________________________________
(атасының исеме(булган очракта)

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
СТУДЕНТЛАР ХЕЗМӘТ ОТРЯДЛАРЫ
ҮСЕШЕНӘ ЗУР ӨЛЕШ КЕРТКӘНЕ ӨЧЕН

*Дигән мактаулы билге*
*белән бүләкләнде*

Таныклык №_____

(Боерык №___ от «__» __________ 20__ года)

Министр _________ ________________________________
(имза) (Ф.И.О.( атасының исеме - булган очракта)
М.П

---

Министерство по делам молодежи
Республики Татарстан

________________________________
(фамилия)

________________________________
(имя)

________________________________
(отчество(при наличии)

*награжден (а)*
*Мактауным знаком*

ЗА ВКЛАД В РАЗВИТИЕ
СТУДЕНЧЕСКИХ
ТРУДОВЫХ ОТРЯДОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

Удостоверение №_____

(Приказ №___ от «__» __________ 20__ года)

Министр _______ ________________________________
(подпись) (Ф.И.О. отчество – при наличии)
М.П.

## IV. «Татарстан Республикасы студентлар хезмәт отрядлары хәрәкәте үсешенә керткән өлеше өчен» мактау билгесе тасвирламасы

«Татарстан Республикасы студентлар хезмәт отрядлары хәрәкәте үсешенә керткән өлеше өчен» мактау билгесе ике яктан да кайма белән уратып алынган, диаметры 32 мм булган сары металл эретмәсеннән ясалган түгәрәк медальдән гыйбарәт.

Медальнең алгы ягында үзәктә ачылган китап сурәтләнгән, аның фальцы (бөгелгән урыны) өстендә төзелеш коралы сурәтләнгән. Китап өстендә җиде почмак рәвешендә нурлары булган кояшның ярымдискы сурәтләнгән, астында 1963 язуы бар. Китапның аскы ягы һәм кырыйлары ике бодай ботагы белән рамланган.

Медальнең икенче ягында аста һәм як-якта ике бодай ботагы белән рамланган «Татарстан Республикасы студентлар хезмәт отрядлары хәрәкәтен үстерүгә керткән өлеше өчен» дигән язу урнаштырылган.

Барлык сурәтләр һәм язулар рельефлы, ялтыравыклы; медальнең төп кыры тонык төстә.

Медаль колакчык һәм боҗра ярдәмендә 26x16 мм зурлыктагы яшел, ак, кызыл төстәге горизонталь полосалар белән тасма рәвешендә эмаль белән сугарылган турыпочмаклы калыпка тоташтырыла.

Ак буй тасма киңлегенең 1/15 өлешен тәшкил итә, ул яшел һәм кызыл төсләрнең тигез киңлектәге полосалары арасында урнашкан.
Калодканың икенче ягында киемгә беркетү өчен төймә бар.

Мактау билгесе макеты

